ГОСУДАРСТВЕННАЯ ЖИЛИЩНАЯ ИНСПЕКЦИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Б.Красная, 15/9, г.Казань, 420111

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ДӘҮЛӘТ ТОРАК ИНСПЕКЦИЯСЕ
Б.Красная ур.15/9, Казан шәһәре, 420111

тел/факс. 236-91-44. E-mail: tatgi@tatar.ru, сайт: www.gji.tatarstan.ru

№ 41

**П Р И К А З** **Б О Е Р Ы К**

«21» март, 2023 ел.

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең 2018 елның 1 ноябрендәге 435 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе тарафыннан күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе норматив хокукый актын Россия Федерациясе законнарына туры китерү максатларында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең 2018 елның 1 ноябрендәге 435 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең 2019 елның 25 декабрендәге 479 номерлы, 2020 елның 3 августындагы 151 номерлы, 2020 елның 16 ноябрендәге 202 номерлы, 2020 елның 17 декаб-рендәге 221 номерлы, 2021 елның 4 июнендәге 90 номерлы, 2021 елның 29 июнендәге 111 номерлы, 2021 елның 18 октябрендәге 168 номерлы, 2022 елның 4 июлендәге
120 номерлы боерыклары керткән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

2. Юридик бүлек җитәкчесенә (Н.Н.Воронская) әлеге боерыкны, дәүләт теркәвенә алу өчен, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

Җитәкче С.А. Крайнов

Татарстан Республикасы
Дәүләт торак инспекциясенең
2023 елның 21 мартындагы
41 номерлы боерыгы белән
расланды

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең 2018 елның 1 ноябрендәге 435 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе тарафыннан күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

2 бүлектә:

2.3 пунктның 2.3.1 пунктчасындагы өченче абзацны көчен югалткан дип танырга;

2.4 пунктта:

2.4.2 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.4.2. Юридик затны үзгәртеп кору, кушылдыру формасында үзгәртеп корган очракларда (үзгәртеп корылган юридик затларның хокуклы варисы дәүләт теркәвенә алынган датага бер үк төрле лицензиягә ия булу шарты белән), лицензиатны башка юридик затка кушылдыру рәвешендә үзгәрткәндә, лицензиатның исемен, лицензиатның урнашу урынын үзгәрткәндә, шәхси эшкуарның исемен, фамилиясен һәм (булган очракта) атасының исемен, шәхси эшкуарның яшәү урынын үзгәрткәндә, шәхси эшкуарның шәхесен таныклаучы документ реквизитлары үзгәртелгәндә, үзгәртеп кору формасында үзгәртелә торган лицензиатның яки кушылдыру яки лицензиатны бу юридик затка кушу рәвешендә үзгәртеп коруда катанаш торган лицензиатның һәм (яки) аның хокуклы варисының һәм (яки) юридик затның «Эшчәнлекнең аерым төрләрен лицензияләү турында» 2011 елның 4 маендагы 99-ФЗ номерлы федераль законның(алга таба – 99-ФЗ номерлы федераль закон) $20^1$ статьясының 1 өлешендә каралган эшчәнлек төрләренең берсен генә булса да гамәлгә ашыруга лицензиясе булган очрактан тыш, ТР ДТИ лицензияләр реестрына дәүләт мәгълүмат системаларыннан алынган мәгълүматны, лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында ТР ДТИ бирелгән мәгълүматтан башка, лицензияләр реестрына үзгәрешләрне автоматик режимда кертү.»;

түбәндәге эчтәлекле пунктчаны өстәргә:

«2.4.7. Бердәм портал, Республика порталы, КФҮ аша дәүләт хезмәте күрсәтү әлеге Административ регламентның 2.4.1 пунктында күрсәтелгән вакыт эчендә гамәлгә ашырыла.»;

2.6 пунктта:

2.6.2 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.6.2. ТР ДТИ, лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында гариза бирмичә, дәүләт мәгълүмат системаларыннан алынган мәгълүмат нигезендә автомат режимда лицензияләр реестрына кертә, түбәндәге очракларда:

1) юридик затны үзгәртеп кору, кушылдыру (кушылдырыла торган юридик затларның һәркайсында үзгәртеп корылган юридик затларның хокукый варисын дәүләт теркәвенә алу көненә шул бер үк эшчәнлек төренә лицензиясе булу шарты белән – күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыру), лицензиатны башка юридик затка кушу рәвешендә үзгәртеп корганда;

2) лицензиатның атамасын үзгәрткәндә;

3) лицензиатның урнашу урыны адресын үзгәрткәндә;

4) шәхси эшкуарның исемен, фамилиясен һәм (булган очракта) атасы исемен үзгәрткәндә;

5) шәхси эшкуарның яшәү урынын үзгәрткәндә;

6) шәхси эшкуарның шәхесен раслаучы документ реквизитларын үзгәрткәндә.

Үзгәрешләрне лицензияләр реестрына кертү ТР ДТИ тарафыннан лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү һәм лицензияләр реестрына кертелә торган мәгълүматларны тикшерү турында карар кабул итүне таләп итми.

Лицензиатның телефон номеры, электрон почта адресы үзгәргән очракта, белешмәләр лицензияләр реестрына Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Лицензияләр реестрын һәм лицензияләр реестрыннан өземтәнең бер төр формасын булдыру һәм алып бару кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 29 декабрендәге 2343 номерлы карары нигезендә лицензиат тарафыннан мөстәкыйль рәвештә кертелә. Лицензияләр реестрына кертелгән телефон номерын, лицензиатның электрон почта адресын үзгәртү турындагы мәгълүматларның дөреслеген тикшерү ТР ДТИ тарафыннан үткәрелми.»;

2.6.9 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.6.9. Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында алына торган документлар (белешмәләр):

дәүләт пошлинасы түләү турында мәгълүмат (Федераль казначылыктан);

Юридик затларның бердәм дәүләт реестрында һәм Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрында (Федераль салым хезмәтеннән) булган мәгълүматлар;

лицензия алырга тиешле вазыйфаи затында икътисад өлкәсендәге җинаятьләр, уртача авырлыктагы җинаятьләр, авыр һәм аеруча авыр җинаятьләр өчен алынмаган яки үтәлмәгән суд хөкеме булуы (булмавы) турында белешмәләр (Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгыннан);

лицензия алырга теләүченең вазыйфаи заты турында лицензиясе гамәлдән чыгарылган лицензиатның бер кулдагы башкарма органы функцияләрен башкаручы затлар, шулай ук лицензиатның уставында яки бүтән документларында күпфатирлы йортта уртак мөлкәтне тиешенчә карап тотуны тәэмин итүгә карата таләпләр үтәлеше өчен җаваплылык йөкләнгән һәм үзләренә карата квалификациясеннән мәхрүм ителү кебек административ җәза кулланылган затлар, лицензиясе гамәлдән чыгарылган һәм (яки) үзләренә карата квалификациясеннән мәхрүм итү кебек административ җәза кулланылган шәхси эшкуарлар реестрында мәгълүмат булуы

(булмавы) турында, шулай ук лицензияләрнең җыелма федераль реестрында лицензия алырга теләүчегә элегрәк бирелгән лицензияне гамәлдән чыгару турында мәгълүматларның булмавы турында белешмәләр (Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгыннан).

Мөрәҗәгать итүче ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында электрон формада тәкъдим ителергә тиешле мәгълүматны үз эченә алган документларны үз ихтыяры белән дә тапшырырга хокуклы.

Югарыда күрсәтелгән белешмәләрдән торучы документларның мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылмавы мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый.»;

2.6.10 пунктчаны үз көчен югалткан дип танырга;

2.7.2 пунктның 2.7 пунктчасында «, КФҮдә» сүзләрен төшереп калдырырга;

2.8 пунктның 2.8.2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.8.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләре:

1) лицензия бирүдән түбәндәге нигезләрдә баш тартыла:

а) лицензия алырга теләүченең лицензия таләпләренә туры килүен бәяләү барышында билгеләнгән лицензия таләпләренә туры килмәве;

б) документар бәяләү барышында билгеләнгән гаризада дөрес булмаган яки ялган мәгълүмат булуы;

2) лицензиянең гамәлдә булу вакытын озайтудан түбәндәге нигезләр буенча баш тарта:

а) лицензиатның лицензиянең гамәлдә булу вакытын озайту турында гариза бирү вакытының үтәлмәве;

б) лицензиатның лицензион таләпләргә туры килүен бәяләү барышында билгеләнгән лицензия таләпләренә туры килмәве;

в) документарны бәяләү барышында гаризада дөрес булмаган яки ялган мәгълүмат булуының ачыклануы;

г) тикшерү уздыру көненә үтәү чоры узып киткән, лицензия таләпләрен тупас бозу очракларын бетерү турында күрсәтмәләрнең үтәлмәү очракларының булуы.

3) әгәр дәүләт серен яки хезмәт серен саклау мәнфәгатьләрендә Россия Федерациясе законнары нигезендә мондый белешмәләрдән ирекле файдалану чикләнгән булса, лицензияләрнең бердәм реестрыннан мәгълүмат бирүдән баш тартыла.»;

2.9 пунктның 2.9.1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.9.1. Дәүләт пошлинасы:

күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензия бирү – 30000 сум;

лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү, лицензиат идарә итә торган күпфатирлы йортлар исемлеген үзгәртү белән бәйле очраклардан тыш, 5000 сум тәшкил итә.

Түләнгән дәүләт пошлинасы, дәүләт пошлинасын түләгән затларның юридик яктан әһәмиятле гамәл кылудан баш тарткан очракта, әлеге юридик әһәмияткә ия гамәлне кылган (кыла торган) вәкаләтле органга (вазыйфаи затка) мөрәҗәгать иткәнчегә кадәр кире кайтарылырга тиеш.

Лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү өчен дәүләт пошлинасы, әгәр 99-ФЗ номерлы федераль законда һәм Административ регламентта каралган очракларда лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү лицензиат тарафыннан мөстәкыйль рәвештә башкарыла икән, түләнми.

2023 елның 1 гыйнварыннан 2023 елның 31 декабренә кадәр бирелгән лицензия бирү, лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү өчен тапшырылган гаризалар буенча дәүләт хезмәтләре күрсәтү кысаларында дәүләт пошлиналары түләү таләп ителми.»;

2.14.2 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Формалаштырылган гарызнамәгә формат-мантыйкый тикшерү Бердәм портал тарафыннан автомат рәвештә, гарызнамәдә электрон форманың һәр кырын мөрәҗәгать итүче тарафыннан тутыру барышында орган (оешма) билгели торган таләпләр нигезендә гамәлгә ашырыла. Бердәм порталда мөрәҗәгатьнең электрон формасындагы кырлар төгәлсезлекләр белән тутырылган булуы ачыкланган очракта, турыдан-туры мөрәҗәгатьнең электрон формасында мәгълүмат җиткерү юлы белән, мөрәҗәгать итүчегә ачыкланган хатаның характеры һәм аны бетерү тәртибе турында хәбәр ителә.»;

3 бүлектә:

3.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә түбәндәге административ процедуралар башкарыла:

1) мөрәҗәгать итүчене консультацияләү;

2) документларны кабул итү һәм теркәү;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган органнарга ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр җибәрү;

4) лицензия бирү турындагы гаризаны карау һәм лицензия бирү (бирүдән баш тарту) турында карар кабул итү;

5) лицензияләр реестрыннан конкрет лицензия турында белешмәләр бирү турындагы гаризаны карау;

6) лицензиянең гамәлдә булу вакытын туктату;

7) лицензиянең гамәлдә булу вакытын озайту турында гаризаны карау һәм лицензиянең гамәлдә булу вакытын озайту турында карар кабул итү;

8) техник хатаны төзәтү.»;

3.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр җибәрү.

Мөрәҗәгать итүченең теркәлгән гаризасы рәсми мөрәҗәгать җибәрү өчен нигез булып тора.

ТР ДТИ ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләрне җибәрү өчен җаваплы булган белгече әлеге Административ регламентның 2.6.9 пунктында каралган

белешмәләрне бирү турында рәсми мөрәҗәгатьләр әзерли һәм җибәрә (шул исәптән электрон хезмәттәшлекнең бердәм ведомствоара системасын кулланып).

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен сорала торган документлар (белешмәләр) исемлеге:

дәүләт пошлинасын түләү турында мәгълүмат. Рәсми мөрәҗәгать Федераль казначылыкка җибәрелә;

Юридик затларның бердәм дәүләт реестрында һәм Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрында булган мәгълүматлар.

Рәсми мөрәҗәгать Федераль салым хезмәтенә җибәрелә;

лицензия алырга теләүченең вазыйфаи затында икътисад өлкәсендәге җинаятьләр, уртача авырлыктагы җинаятьләр, авыр һәм аеруча авыр җинаятьләр өчен алынмаган яки үтәлмәгән суд хөкеме булуы (булмавы) турында белешмәләр. Рәсми мөрәҗәгать Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгына җибәрелә;

лицензия алырга теләүченең вазыйфаи заты турында лицензиясе гамәлдән чыгарылган лицензиатның бер кулдагы башкарма органы функцияләрен башкаручы затлар, шулай ук лицензиатның уставында яки бүтән документларында күпфатирлы йортта уртак мөлкәтне тиешенчә карап тотуны тәэмин итүгә карата таләпләр үтәлеше өчен җаваплылык йөкләнгән һәм үзләренә карата квалификациясеннән мәхрүм ителү кебек административ җәза кулланылган затлар, лицензиясе гамәлдән чыгарылган һәм (яки) үзләренә карата квалификациясеннән мәхрүм итү кебек административ җәза кулланылган шәхси эшкуарлар реестрында мәгълүмат булуы (булмавы) турында, шулай ук лицензияләрнең җыелма федераль реестрында лицензия алырга теләүчегә элегрәк бирелгән лицензияне гамәлдән чыгару турында мәгълүматларның булмавы турында белешмәләр. Рәсми мөрәҗәгать Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгына җибәрелә.

Әлеге органнарга ведомствоара мәгълүмат сорау турында рәсми мөрәҗәгать ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасын һәм аңа тоташтырыла торган ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең региональ системаларын кулланып, мөрәҗәгать итүчегә  дәүләт хезмәте күрсәтү максатында җибәрелә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар гаризаны һәм гаризага теркәлгән документларны теркәгән көнне башкарыла.

Административ регламентның 2.6.9 пунктында каралган белешмәләр ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр буенча әлеге документлар белән эш итүче органнар тарафыннан электрон формада, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек итү кагыйдәләрен, шул исәптән Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте башкарма органнары һәм (яисә) җирле үзидарә органнары арасында ведомствоара мәгълүмат хезмәттәшлекне оештыруның киңәш ителә торган кагыйдәләрен раслау һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларын һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 2021 елның 23 июнендәге 963 номерлы карары нигезендә ведомствоара гаризаны юллаган вакыттан башлап 48 сәгатьтән артып китмәгән чорда бирелә.

Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кәгазь чыганакта башкарылырга мөмкин:

сорала торган белешмәләр электрон формада булмауга бәйле рәвештә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлекне электрон формада гамәлгә ашырып булмаган очракта;

ведомствоара рәсми мөрәҗәгать җибәргәндә, кәгазь чыганакта документларның оригиналларын тапшырырга кирәк булганда.

Әгәр ведомствоара хезмәттәшлек кәгазь чыганакта гамәлгә ашырылса, Административ регламентның 2.6.9 пунктында каралган белешмәләр әлеге белешмәләрне үз эченә алган документлар белән эш итүче органнар тарафыннан бирелә.

210-ФЗ номерлы федераль законның $7^2$ статьясының 3 өлеше нигезендә ведомствоара гаризаларга җавап әзерләү һәм җибәрү срогы ведомствоара рәсми мөрәҗәгать алынган көннән башлап биш эш көненнән артырга тиеш түгел.

Процедураның нәтиҗәсе: белешмәләр бирү турында җибәрелгән рәсми мөрәҗәгатьләр, сорала торган документларны (аларның күчермәләрен яки аларда булган белешмәләрне) алу.

Белешмәләрне кулланунының максатлары булып мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган документларның дөреслеген билгеләү, шулай ук законнарны һәм мөрәҗәгать итүченең хокукларын бозу очракларын булдырмый торган карарлар кабул итү тора.»;

3.6 пунктны көчен югалткан дип танырга;

Административ регламентның 10 нчы кушымтасында «баш тартуга карата суд тәртибендә шикаять бирелергә мөмкин» сүзләрен «баш тарту судка кадәрге тәртиптә шикаять ителергә мөмкин» сүзләренә алмаштырырга;

Административ регламентның 15 нче кушымтасында «баш тартуга карата суд тәртибендә шикаять бирелергә мөмкин» сүзләрен «баш тарту судка кадәрге тәртиптә шикаять ителергә мөмкин» сүзләренә алмаштырырга;

Административ регламентның 17 нче кушымтасында «баш тартуга карата суд тәртибендә шикаять бирелергә мөмкин» сүзләрен «баш тарту судка кадәрге тәртиптә шикаять ителергә мөмкин» сүзләренә алмаштырырга.